**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2019 № 944

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы, 30.11.1994 ел, № 51-ФЗ (алга таба - РФ ГК) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 05.12.1994, № 32, ст. 3301);

Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 ел, № 136-ФЗ (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 29.10.2001, №44, ст.4147);

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында» 1996 елның 1 апрелендәге 27-ФЗ номерлы Федераль закон (01.04.1999 ред.) (алга таба – 27-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 01.04.1996, № 14, ст. 1401);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 06.10.2003, №40, ст.3822);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 02.08.2010, №31, ст.4179);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасын һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең һәм җир кишәрлекләренең урнашу схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында урнашу схемасын, җир кишәрлегенең һәм җир кишәрлекләренең кадастр планында урнашу схемасын әзерләүгә карата таләпләрне раслау турында» 2014 елның 27 гыйнварындагы 762 номерлы боерыгы (алга таба – 762 номерлы боерык) (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 18.02.2015);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Сатуларны үткәрмичә генә җир кишәрлеге сатып алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» гы 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы (алга таба- 1 номерлы боерык) (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Кама Тамагы муниципаль район Советының 2005 елның 8 декабрендәге 19 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Кама Тамагы муниципаль район Советының 2006 елның 1 февралендәге 32 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә, (алга таба – Башкарма комитеты турында Нигезләмә);

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 29 мартындагы 36 номерлы карары белән расланган Палата турында нигезләмә (алга таба – Палата турында Нигезләмә);

Башкарма комитетның 2015 елның 11 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).»;

2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә әлеге документлар карамагында булган оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең шәхси счетының (Россия Федерациясе Пенсия фондында) иминият номеры турында белешмәләр, шулай ук хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның категориясенә карап, 3 номерлы кушымта нигезендә документлар һәм белешмәләр алына.<br>Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый. | 27-ФЗ номерлы Федераль закон<br><br>1 номерлы боерык |

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин